**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, поселогы,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**10 август, 2022 ел** **№ 186**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Бөреле авыл җирлегенең Генераль планын раслау турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясындагы 13 өлеше, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Биектау муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Бөреле авыл җирлегенең Генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар беркетмәләрен һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәләрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Бөреле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең кушымтада бирелгән Генераль планын расларга.
2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетына территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Бөреле авыл җирлегенең Генераль планын урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, җирле үзидарә һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының җәмәгатьчелек белән элемтә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе урынбасары,
муниципаль район Башлыгы урынбасары Ә.Ш. Шакиров

Бөреле авыл җирлегенең Генераль планы материаллары белән https://fgis-tp.ru сайтында танышырга мөмкин.